Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«22» октябрь, 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Тогаево авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле Калинин авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500(биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге юлларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә электр белән тәэмин итүне оештыру (яктырткычлар һәм электр җиһазлары сатып алу, монтажлау);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (тротуарны төзекләндерү);
- ял итүне оештыру һәм авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру (ноутбук сатып алу);
- торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итүне оештыру (реконструкция);
- торак пункт территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру (ТАССРның 100 еллыгы паркында волейбол мәйданчыгын төзекләндерү);
- зиратны саклау өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру

2. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Иске Җирекле авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев